АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2025 № 25

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 2024 елның 02 февралендәге 233 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставына туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде**:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 2024 елның 02 февралендәге 233 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6.1 пунктның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларыннан тыш; югары белем яисә урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск район Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Ю. Монинага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С. А. Демидов**